ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Тукай ялкыны

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры **Февраль, 2024 нче ел** №5




**Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның Ватанны саклаучылар көне уңаеннан мөрәҗәгате.**

Хөрмәтле татарстанлылар, кадерле ветераннар!

Бүген безнең илебез иң әһәмиятле дәүләт бәйрәмнәренең берсе – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә.

Бу тантанада Россиянең ватанпәрвәрлеккә һәм халкыбызның бердәмлегенә нигезләнгән данлыклы һәм бөек көрәшләре, җиңүләре тарихы ачык чагылыш таба.

Бөек Ватан сугышында, олы сынаулар узып, Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклап калган кадерле ветераннарыбызны бу бәйрәм уңаеннан аеруча җылы хисләр белән тәбриклим. Сезнең батырлыгыгыз, илебезгә булган чиксез мәхәббәтегез һәм тугрылыгыгыз турында якты хәтер безнең өчен һәрчак иң югары әхлакый маяк булып тора. Без бу изге хатирәләрне мәңге күңелләребездә саклярбыз һәм буыннан-буынга тапшыра килербез.

Локаль сугышларны һәм низагларны җайга салу, тынычлык миссияләрен үтәү барышында үз бурычларын лаеклы башкарган барлык ватандашларыбызга олы рәхмәтемне белдерәм.

Россия Федерациясе Кораллы көчләренең Югары башкомандующие Владимир Владимирович Путин җитәкчелегендә сугышчыларыбыз үзләренең хәрби бурычын бүгенге көндә махсус хәрби операция уздыру зонасында, Ватанга ихлас хезмәт итү үрнәге күрсәтеп, батырларча үти. Сезгә зур хөрмәт һәм рәхмәт хисләремне җиткерәм. Илебез сезнең белән горурлана.

Ватанны саклаучыларны, аларның гаиләләрен, мөхтәрәм ветераннарыбызны, шулай ук барлык татарстанлыларны бәйрәм белән котлыйм. Сезгә нык сәламәтлек, рухи ныклык, иминлек, бәхет һәм уңышлар телим.

Тулырак: https://shahrikazan.ru/news/%D2%97%D3%99mgyiyat/rostam-minnexanov-vatanny-saklaucylar-kone-belan-kotlady

**Ватанны саклаучылар көне уңаеннан район Башкарма комитеты җитәкчесе Альберт Хуҗин котлавы**

Хөрмәтле Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәт һәм хәрби хезмәт ветераннары, ил сагында торучы солдатларыбыз, хөрмәтле ир-егетләребез!

Бәйрәм белән!

23 февральдә Ватанны саклаучылар көнен билгеләячәкбез. Район Башкарма комитеты җитәкчесе Альберт Хуҗин сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, армия сафларында хезмәт итүчеләргә, барлык ир-егетләргә тәбрикләү сүзләрен җиткерде. Анда мондый юллар бар: “Ватаныбыз тарихының бар чорында ир-егетләребез ил чикләрен сакладылар, батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Бу көнне без Кораллы көчләрнең барлык буынын хөрмәтлибез. Батырлыклары һәм хәрби традицияләрне саклауга керткән лаеклы өлешләре өчен Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарына, хәрби-нтернационалистларга, запастагы солдатларга һәм офицерларга тирән рәхмәтебезне җиткерәбез. Без хәрби бурычларын намус белән үтәүче яшьләр белән хаклы горурланабыз. Тыныч күк йөзе астында бәхетле, матур яшик!”

Тулырак: [https://muslumirc.ru/news/stati/vatanny-saklauchylar-kne-uaennan-rayon-bashkarma-komitety-itkchese-albert-khuin-kotlavy](https://muslumirc.ru/news/stati/vatanny-saklauchylar-kne-uaennan-rayon-bashkarma-komitety-itkchese-albert-khuin-kotlavy)







**Мәктәп яңалыклары...**

20 февраль көнне гимназия базасында инглиз телендә "English Fest" фестивале үтте. 17 мәктәп инглиз телендә инглиз язучыларының әсәрләреннән театр күрсәттеләр. Мәктәбебезнең "Wonderland" театр коллективы абсолют җиңү яулады. Укучыларыбыз сәхнәдә инглиз телендә иркен сойләшүләре, матур костюмнары белән тамашачыны таң калдырдылар.



19 февраль көнне оешма һәм предприятиеләр арасында XXXIV спартакиада ярышларына старт бирелде. Укытучыларыбыз, мәктәпләр җыелма командасы составында, кул көрәше, канат тарту ярышларында катнашты.





Рус мәктәпләренең рус төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен үткәрелгән татар теле буенча республика олимпиадасының йомгаклау этабында 7 нче сыйныф укучысы Паймуллина Есения призёр булды. Укытучысы: Гөлшан Мәүлиева. Уңышларыгыз белән котлыйбыз!..

**Әтиләр сүзе- күңелнең күзе**

Әтиләр сүзе - күңелнең күзе..Ил терәге-ир-егет булса, гаилә терәге әтиләр.Гаиләдә эти төп таяныч, терәк булып тора. Бала тәрбияләүдә әтиләрнең йогынтысы бик зур.

- Хәерле көн, хөрмәтле әтиләр, балалар, укучылар, кунаклар! Бүген без сезнең белән Ватанны саклаучылар көненә багышланган кичәгә җыелдык. Кадерле әтиләребез һәм алмашка үсүче малайларыбыз! Без сезнең барыгызны да бәйрәм белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә алдагы тормышыгызда зур уңышлар, корычтай нык сәламәтлек, озын гомер телибез. Сез, әтиләр, гаилә башлыгы буларак, гаиләне яклаучы, туендыручы, яшәү шартларын булдыручы. Әти кешенең күп вакыты йорттан читтә – хезмәттә үтә. Бүген менә кичәгә килүегез өчен бик зур рәхмәт.Ә хәзер кичәбезне башлап җибәрергә рөхсәт итегезБу очрашуда без бер-беребез турында күбрәк белербез, балалар тәрбияләүдә булган тәҗрибәләр белән уртаклашырбыз, балаларыбыз белән горурланып утырырбыз, ә алар үз чиратында сезгә булган хөрмәтләрен күрсәтерләр. **Әтиләр тиз генә уйлап җавап бирик әле, сезнең иң бәхетле чагыгыз кайчан иде?** Яхшылап уйлагач– иң бәхетле чак - балачак дигән нәтиҗәгә килгәнсездер. Ул чакта агачлар биегрәк, кояш-яктырак, җәй - озынрак, кызлар – чибәррәк иде. Беренче сөенечләр, көенечләр, беренче уңышлар һәм җиңелү яшьләре. Боларны без балачакта кичерәбез. Балачак безне тормышка өйрәтә, шулардан беренче тәҗрибә туплана.
**Кем булырга хыяллана идегез?**-Кемнәр генә булырга хыялланмаган безнең әтиләр малай чакларында?!Министр,начальник,президент,шофер,очучы...
**Балачакта безнең әтиләребез нәрсәләр яратып ашадылар икән? "Әтиең белән киңәшләсеңме?"** дигән сорауга мәктәптә укучы барлык балалар да уңай җавап бирәләр. Бу шулкадәр куандыра торган хәл. Димәк, безнең әтиләр – балаларын, балалар - әтиләрен аңлыйлар. һәрвакыт яхшы бул, хезмәт сөй, тырышып укы, тәртипле бул, олыларны хөрмәт ит, чын егет бул, әниеңә ярдәм ит, әдәпле, тәүфыйклы бул, каршы әйтмә, бер кеше белән дә талашма, беркайчан да ялган сөйләмә, кешенең сиңа яхшылык эшләгәненонытма!-диләр.
**Әйе, бала тәрбияләүдә вак-төяк була алмый. Вакытында әтисе, абыйсы, бабасы тарафыннан бирелгән яхшы киңәш баланың киләчәген билгели. Яхшы киңәш биреп әти-әни үзенең бәхетле картлыгына нигез сала.Халык гаиләдә атаның урынын югары бәяли. Әти кешенең сабырлыгы, һәр сүзен уйлап сөйләве, җаваплы кешеләргә итәгатле булуы, иҗтимагый активлыгы игътибарга лаек. Халык авыз иҗатында һәм педагогикасында ата кеше гаиләне саклаучы итеп күрсәтелә. Ата кешенең күп вакыты йорттан читтә - хезмәттә үтә. Бер үк вакытта ата – аек акыл иясе дә. Ул булмасатормышныңрәтекитә башлый.**
"**Әтиең сине нәрсәләргә өйрәтә?"**-Әйе бер генә эшнең дәояты юк. Баланы хезмәткә җәлеп итү аңарда бик күп уңай сыйфатлар тәрбияли, һәр эш авыр, әмма көчтән килерлек булсын. Шул чакта гына балагыздла үз көченә ышаныч туачак, хезмәткә мәхәббәт уяначак. Түземлелек, шәхси үрнәк, уртак эшчәнлек, мактау сүзләре сезгә балагызны тәрбияләргә ярдәм итәчәк. әгәр аның турында, хезмәт сөючәнбаладипәйтсәләр,моныузурҗиңүегездипкабулитегез.
**Буш вакытларында безнең әтиләребезнең иң яраткан шөгыле** Ир-егет булу кыен. Чөнки ул, барыннан да элек, төрле хәлләрдә үзеңә җаваплылык алуны аңлата. Балаң, хатының, яраткан эшең өчен җаваплылык тою ир-атның гомерлек горурлыгы булып калырга тиеш. Бәхеткә, мондый әтиләр теливизор экраннарында гына түгел, тормышта да бик күп. - әтиләр, балаларыгыз сезнең менә нинди сыйфатларыгызны ошаталар:эшчән, сүзендә торучан булуы, ярдәмчеллеге, таләпчәнлеге, куйган максатына ирешә алуы, кешене , әнине хөрмәт итүе Әтиләрне сайлап алмыйлар.Ләкин безнең әтиләрнең барысы да хөрмәткә лаек булуы безне сөендерә. Бала тәрбияләү өлкәсендә без бу әтиләргә ныклап таяна алабыз. Алар һәрберсе үзенчә әйбәт, үзенчә яхшы. Балаларның сезнең яхшы якларыгызны күрәбелүләрешулайуктәрбиянәтиҗәсе.
**"Син әтиеңне ни өчен яратасың?" укучыларга сорау** Күргәнебезчә, балаларыгыз сезнең турында бик югары фикердә. Алар сез эшләгән яхшылыкны күрә һәм бәя бирә беләләр. Әтиләр! Шушы хөрмәтне саклапкалусезнеңбурычыгыз.
**Әтиләргә киңәшләр язылган открыткалар тарату.**Әти кеше!Исеңдә тот: гаиләдә уңай атмосфера тудыру-синең изге бурычың.Баланың укуга, эшкә сәләте аның иртәнге кәефе, гаиләдәге шартларга бәйле. Иртән үк аның кәефен бозмаска тырышыгыз.Мәктәпкә бергә барырга мөмкинлегегез булса, бу моментны файдаланыгыз.Мәктәптән кайткан балагызны: "Нинди билге алдың ?",-дип түгел, "Мәктәптә хәлләр ничек, ни белән шөгыльләндегез?", -дип каршылагыз.Балагызның аз гына уңышында да чын күңелдән сөенегез.Уңышсызлыкка очраса, ачуланмагыз, ярдәм итегез.Бала үзен яратуларын һәрдаим тоеп торырга тиеш.Кычкыру,тупас интонацияләр онытылсын. Гаиләгездә шатлык, бер-береңә хөрмәт, ярату хөкем сөрсен.Йомгаклау. ҺӘР ӘТИ, ҺӘР БАЛА ҮЗЕ БЕР серле сандык. Әгәр без бүгенге кичәдә шушы сандыкларны ачып, андагы хәзинәне сезгә бераз гына күрсәтә алсак максатыбызга ирешкән булырбыз.Без- кешеләр- җиргә иҗат итәр, сөяр-сөелер, гаилә корып, тәрбияле балалар үстерер өчен туганбыз. Көнкүрешебездә нинди генә кыенлыклар булса да , бу дөньяга ник килгәнебезне онытмыйк.Хөрмәтле әтиләребез!Безнең балаларыбызга булган ихтирамыбыз сүнмәсен иде! Сез-балаларыгызның, балалар- сезнең мәңге иң кадерле кешегез булып калсыннар! Бәхетле булыгыз!

**Кичәбезнең 2 өлешендә** без уйнарбыз, беләкләрнең көчен, йөрәкләрнең дәртен сынарбыз. Шулай ук, теманың асылына төшену өчен берничә сорауга да җавап бирербез. Сорауларга уйлап җавап бирергә тырышыгыз, шул ук вакытта, әтиләрегезнең сүзен игътибар белән тыңлагыз. Чөнки бүгенге сөйләшүнең девизы: **«Әтиләр сүзе –күңелнең күзе».**Кадерле укучылар! Менә бит бәйрәмгә әтиләр килгәч нинди күңелле, әйеме. Кайчандыр сезнең әтиләр дә сезнең кебек булганнар, мәктәптә укыганнар, сезнең кебек шаярганнар, көлгәннәр, рәхәтләнеп уйнаганнар. Бәлки кайберләре үткән балачакны онытканнардыр да инде. Ә шулай да без аларга балачакның бәхетле мизгелләрен искә төшерергә булышыйк әле. Сез ризамы, әтиләр? Алай булса, мин сезгә иң элек бер табышмак әйтәм, тыңлагыз:Канаты бар – җилпеми, Эче җылы – җил тими.Кырык йөрәкле кош ул, Безнең яраткан дус ул.(самолет)Дөрес, хәзер без сезнең белән самолетлар ясыйбыз.

**1. Ике эти чыга. Кәгазьдән өчәр самолет ясыйлар, кем тизрәк? Шушы әтиләрнең балалары чыга. Әтиләре тоткан боҗрага самолетларны кертергә тырышалар. Кемнеке күбрәк керә?**Укучылар өчен сорау:**Чын ир-егет нинди булырга тиеш?** ( Сәламәт, акыллы, көчле, киң жилкәле, батыр, кыю һ.б._)Бик дөрес фикерләр әйттегез.Нәкъ менә шундый сыйфатлар сезнең әтиләрегезгә дә хас. Алар гаиләнең башлыгы, сезне киендерүче, ашатучы, саклаучы һәм яклаучы. Сез алар белән горурлана аласыз.Балалар, сез әтиләрегез белән табигать кочагына чыгарга яратасызмы? Менә шулай сез урманга бардыгыз, ди. Сезгә кечкенә елга очрады, ди. Әтиләр шул вакытта сезне күтәреп алып чыга алырлар микән?



Мәктәптә Әфганстан Демократик Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруның 35 еллыгына багышланган Батырлык дәресе узды. Әфганстандагы ун еллык сугыш 15000 яшь кешенең гомерен өзгән, аларның күбесенә 19 яшь тә тулмаган була.
Чарада кунак Солтанов Алмаз Мизхәт улы катнашты.Балалар ДРАда Татарстанның һәлак булган кешеләре турында видеороликлар карадылар. Очрашу барышында укучылар кунакка үзләрен кызыксындырган сораулар бирделәр..



Хезмәт һәм сугышчан дан мемориаль комплексында тантаналы митинг узды. Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгаруның 35 еллыгы уңаеннан оештырылган чарада мәктәп җитәкчелеге, укытучылар һәм укучылар катнашты. Тантаналы чара яу кырында башын салган якташыбыз Фаиз Рашитов каберенә чәчәкләр салу белән төгәлләнде.



14 нче февраль көнне мәктәбебездә ТР Дәүләт Советы депутаты, Дәүләт Советы рәисенең урынбасары Марат Готуф улы Әхмәтов, ТР Мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Минзәлия Заһри кызы Закирова, Мөслим муниципаль районы башлыгы Альберт Роберт улы Хуҗин булдылар. Кунаклар парламент дәресендә катнаштылар, илдәге вәзгыять, республика тормышы турында сөйләделәр, укучыларыбызның сорауларына җавап бирделәр.



3. **«Балаларны елга аша алып чык».**

**4. - Хәзер әтиләр белән дә әзрәк шаярып алабыз. Уенга 3 әти чыга. Менә шушы шарларны кем шартлатмыйча зуррак итеп кабарта ала?**

**6. Кабартылган шарларны балалар бергә шартлата**

**7. Тапкырлар, зирәкләр**

Суда нинди таш булмый? (Коры).

Нинди сорауга бервакытта да «әйе» дип җавап биреп булмый? (Йоклыйсыңмы?).

Алманың яртысы нәрсәгә охшаган? (Икенче яртысына охшаган).

Кешегә иң якын әйбер? (Күлмәк).

Борынгы заман сәгате? (Әтәч)

Ашлыкны ни өчен чәчәләр? (Утыртып булмаганга).

Кәҗәнең башында нәрсә бар? (К хәрефе бар).

Ат нигә улак янына килә? (Улак үзе килмәгәнгә).

Кайсы ай календарда юк (куктеге)

Сыйныфтагы өстәлләр( парта)

Нинди кошлар хат ташучы булалар?(күгәрчен)

Алтын таракның төшеп калган урыны(басма0

Сәгатьтә өч цифрына каршы нинди цифр тора?(9)

Почтальон Печкин нинди транспорта йөри? (велосипед).

Шифалы эчемлек , көндә кулланабыз(чәй)

Футбол командасында ничә уенчы (11)

**8. Бәрәңге әрчү бәйгесе. (малайлар)**

**9.«Дөрес әйт» бәйгесе игълан ителә**. Әти күзләрне бәйләгән килеш үз малаен табарга тиеш.

-Әниләребез эштә чакта әтиләргә кечкенә малайларын ,кызларын ашатып алырга да туры килгәндер

**10. Кукурузная палочка ашаталар( әтиләрнең күзләре бәйләнгән)**

**11. Кем тизрәк –малайларның күзләре бәйләнгән , аяк киемнәрен тыбып киерге тиешләр.**

**12.Малайлар өчен Анкета.**

1. Әтиеңнең туган көне, елы, туган җире. 2. 2. Әтиең кайда эшли? Кем булып? Эшен яратамы? 3. әтиең армиядә хезмәт иткәнме? Кайда? Кем булып? 4. Әтиең балачакта кем булырга хыялланган? 5. аның балачакта яраткан ашамлыгы, конфеты? 6. Мәктәптә укыганда нинди фәннәрне яратмаган? 7. Ә нинди фәннәрне яратып укыган7 8. әтиеңнең балачактагы кушаматы- 9. Әтиеңнең иң яхшы дустының исеме- 10. Өйдә син кем белән күбрәк аралашасың? Ни өчен? 11. Әтиең белән киңәшләшәсеңме? 12. Ул сиңа нинди киңәшләр бирә7 13. Ул сине нәрсәгә өйрәтә? 14. Буш вакытларында әтиеңнең яраткан шөгыле- 15. Әтиеңнең нинди сыйфатлары сиңа ошый? 16. Әтиең сиңа дәрес әзерләшергә булышамы? 17. Аның белән бергә китап, газеталарукыйсызмы, кроссворд, сканвордлар чишәсезме? 18. Әтиең синең дусларыңны беләме? 19. Әтиеңә эч серләреңне сөйлисеңме? 20. Әтиең белән әниең ничә ел бергә гомер кичерәләр? 21. Әтиең турында син нәрсәләр уйлыйсың? 22. Син әтиеңне яратасыңмы? Ни өчен? 23. Әтиеңә теләкләрең.

**13. Әтиләр бии (кассеталар газетага төрөлгән)**- бернечә әти чыгып сайлап ала.

**14. «Катюша» җырын төрлечә җырларга (песи, эт,**

**15. – Һәр кеше иртән эшкә ашыга:** Кейенер вакытта гына ут сүнә. Баланың киемнәрен алып аны киендерергә кирәк.

Очрашуыбыз ахырына якынлаша. Балалар, үзегезнең әтиләрегезнең чын Ир-егет булуларына тагын бер кат ышандыгыз. Алар көчле дә, кыю да, житез дә булуларын расладылар. Сез дә алардан калышмадыгыз, сынауларны үти алдыгыз.

Димәк, сез, чыннан да әтиегез белән чын Ир-егет икәнсез.

-Хөрмәтле әтиләр. Менә безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Сезне Ватанны саклаучылар көне белән тагын бер тапкыр котлыйбыз. Без сезгә ышанабыз, без сезне яратабыз, без сезнең белән горурланабыз. Сез безне һәм туган илебезне күз карасыдай якларга һәм сакларга һәрвакыт әзер. Ләкин безгә афәтләр күрергә язмасын иде, ә балалар белән гаиләдә куанышып яшәргә язсын. Һәрвакыт сәламәт булыгыз! Балаларыгыз белән бүгенге кебек дус, тату, күңелле, бер-берегезне аңлап гомер итегез.

**10 а сыйныфы җитәкчесе Әсәдуллина Йолдыз Рәис кызы**



















# Укучыларыбыз иҗаты

**9"б"сыйныфы укучылары яза...**

**Ватанны яклаучылар кемнәр алар?**

Ватанны саклаучылар - үз ватаннарын яклау һәм иминлеге өчен җаваплылыкны үз өстенә алучы кешеләр төркеме. Бу кешеләр хәрби, хокук саклаучылар, гражданнар активистлары яки үз илендә тынычлык һәм иминлек сагында торырга әзер гражданнар булырга мөмкин. Ватанны саклаучыларның роле җәмгыять һәм милли иминлек өчен мөһим.Ватанны саклау - теләсә кайсы дәүләтнең иң мөһим бурычларыннан берсе. Үз илен якларга кирәкме дигән сорау һәрвакыт төрле карашлар һәм дискуссияләр тудыра. Әмма ватанны саклау кирәклеге файдасына бик күп дәлилләр бар.Барыннан да элек, Ватанны яклау һәр гражданның бурычы булып тора. Һәр илдә чикләрне һәм милли мәнфәгатьләрне яклау өчен хезмәт итүче коралны көчләр бар. Тиешле сакланудан башка, дәүләт башка илләр яки эчке конфликтлар тарафыннан мөмкин булган янаулар алдында көчсезләнә. Ватанны саклау гражданнарның иминлеген һәм иминлеген тәэмин итә, шулай ук илнең суверенитетын һәм бәйсезлеген саклый.

**Муглиев Ибраһим**

Ватанны яклаучылар - ул үз илләрен яклау өчен тормышын бирергә әзер кешеләр. Бу хәрби хезмәткәрләр, янгын сүндерүчеләр, медицина персоналы, полицейлар, шулай ук куркыныч булган очракта ярдәм итәргә әзер гадәти гражданнар булырга мөмкин.Ватанны ни өчен саклауга кирәк? Беренче һәм төп сәбәп - ул үз иленең иминлеген тәэмин итү һәм аның милли мәнфәгатьләрен яклау. Ватанны яклаучылар ватанының игелеге өчен эшли, аны эчке һәм тышкы куркынычлардан, террористик актлардан, башка дәүләтләрнең агрессиясеннән саклый. Алар үз халыкларының азатлыгы, демократиясе һәм хокуклары өчен көрәшергә әзер.Минем уземнең армиягә бик барасы килә. Мин, чын егет, чын ватан саклаучы булып кайтасы килә.

**Вәлиев Алим**

Күп гасырлар дәвамында Ватанны яклау күп кешеләр өчен мөһим һәм мактаулы бурыч булып тора. Ватанны саклаучылар арасында хәрби хезмәткәрләр, гражданнар оборонасы кешеләре, патриотлар һәм туган якларын эчке һәм тышкы куркынычлардан сакларга әзер кешеләр булырга мөмкин.

Хәрби хезмәткәрләр дәүләтне тышкы агрессорлардан һәм террористик куркынычлардан саклауда төп роль уйныйлар. Гражданнар оборонасы ил куркынычсызлыгын тәэмин итүдә дә мөһим роль уйный. Бу янгын сүндерүчеләр, фельдшерлар, гадәттән тыш хәлләр белән идарә итүчеләр һәм төрле афәтләргә һәм кризис хәлләренә тиз җавап бирергә әзер булган бүтән хезмәткәрләрне үз эченә ала. Ватанны яклаучылар - хәрби форма кигәннәр генә түгел, ә үз илләренең иминлеге һәм куркынычсызлыгы өчен эш итүчеләр. Аларның фидакарьлеге, тугрылыгы һәм хезмәт итәргә әзерлеге аларны чын герой, ватанны саклаучылар итә.…

**Исмәгыйлев Даян**

Кем соң ул Ватан саклаучылары ? Ватанны саклаучылар-барлык авырлыкларга карамастан, үз Ватаннары өчен куркынычларга барырга әзер кешеләр .Андый кеше ботен авырлыкларны үтеп уз ватанын сакларга әзер. Алар бик кыю һәм җавапли кешеләр . Ватанны сакларга кирәк, чөнки Ватан ул туган , үскән урын . Ватан кеше тормышының иң мөһим өлешләренең берсе, шуңа күрә аны якларга кирәк . Армиягә барасым килә. Минемчә, армия сине каты тормышка әзерли һәм син тормышка җитдирәк карыйсың . Син үз Ватаныңны сакларга әзер булачаксың.

**Зайдуллин Самат**

Ватанны саклаучылар кем икәнен беләсезме? Бу кыю кешеләр бөтен гомерләрен туган якларын саклауга багышлыйлар. Аларның төп бурычы - безнең тынычлыкны һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү. Рәсәй тарихында илебезнең кыю һәм кыю яклаучыларының бик күп лаеклы үрнәкләре бар. Батырлык һәм кыюлык безнең кешеләргә дошманнар һәм басып алучылар алдында чигенергә рөхсәт итмәде, һәм Бөек Ватан сугышы моны бик яхшы күрсәтә. Күпләр, гомерләре өчен, нацистларга җир алырга һәм дошманнарны илдән куарга рөхсәт итмәделәр. Аннары күп кеше чын герой булды.

**Камалетдинов Инсаф**

Тиздән минем кулымда мәктәпне тәмамлау турында аттестат булачак, барысы да уйлана башлый һәм кая барырга икәнен хәл итә, ләкин миңа моны эшләргә кирәкми, чөнки мин киләчәк язмышымны һәм тормышымны хәл иттем. Мин хәрби булырга телим. Нәкъ менә шундый минем һөнәрем булачак, хәрби булу шактый авыр, мондый сыйфатларга ия булырга кирәк: Игелек һәм хөрмәт, гадел булу, әмма шул ук вакытта үз ныклы принципларың булу. Хәрби үз Ватанының патриоты булырга тиеш, бу кайвакыт җиңел түгел, чөнки кайбер очракларда Илне яклау яки гаиләне яклау турында сорау туарга мөмкин. Хәрби, чын хәрби булу-бу чакыру һәм бу һәркемгә дә мөмкин түгел, шуңа күрә мондый карар кабул иткәнче яхшы уйларга кирәк.

**Хафизов Булат**

Һәр ел саен кыш ахырында халкыбыз истәлекле датаны билгеләп үтә. Бу ирләр бәйрәме- Ватанны саклаучылар көне. Бу көнне без әтиләребезне, абыйларыбызны, бабаларыбызны, бабаларыбызны котлыйбыз.Чынлыкта, әлеге бәйрәмнең мәгънәсенә җитди карасаң, беренче чиратта Ватанны саклауга кагылышлы ир-атларны котларга кирәк. Мәсәлән, хәрбиләр, полиция хезмәткәрләре, махсус хезмәтләр хезмәткәрләре, коткаручылар, янгын сүндерүчеләр, табиблар. Әлбәттә, армиядә хезмәт иткән барлык ир-атлар.Чөнки элек, Советлар Союзында, 23 февраль Совет Армиясе көне булган. Ул вакытта барлык ир-атларны диярлек армиягә чакырырга кирәк иде. Хәзер армиядә барлык егетләр дә хезмәт итми.Ләкин халыкта 23 февраль белән барлык ир-атларны, хәтта малайларны да котлау гадәти хәл. Чөнки һәр ир-ат, кирәк булса, Ватанны саклаучы була ала. Мәсәлән, сугыш яки табигать афәте булса. Әгәр дә көчсезләргә һәм яклаусызларга, хатын-кызларга, картларга һәм балаларга куркыныч яныса, һәр чын ир-ат аларның яклаучысы булачак.

**Кәримов Ильяс**

Ватанны саклаучы кем ул? Бу чын ир-ат сугышчы, батыр һәм затлы рыцарь. Ул көчсезләрне коткара, дошман алдында калтырап тормый. Мондый кеше хәрби яки полиция хезмәткәре булырга мөмкин. Ләкин аның кулында корал тоту мәҗбүри түгел, шуңа күрә Ватанны саклаучы табиб, коткаручы яки янгын сүндерүче дә булырга мөмкин. Ләкин кеше патриот булмаса да, ул Ватанны яклауга күтәрелергә тиеш - бу аның РФ Конституциясендә язылган гражданлык бурычы. Анда, башка сүзләр белән әйткәндә, үз Ватанын саклау - ул бер үк вакытта бурыч та дип язылган .Мин армиягә барасым килә, чөнки армия каты тормышка өйрәтә, һә м Ватанны сакларга әзерли.

**Ханов Ранис**

«Тукай ялкыны", февраль, 2024 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф. Корреспондентлар Нуреева Алия, Җаббарова Диана Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр.